# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлеге Татар Мөшегесе торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

**10.11.2023 ел** **№ 12**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 10.11.2023 елда гражданнар җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:«2024 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Татар Мөшегесе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

1) Татар Мөшегесе торак пунктында авыл паркы территориясен төзекләндерү (койма урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 160 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 86 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 86 катнашучы тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегендә Татар Мөшегесе торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга::«2024 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Татар Мөшегесе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

1) Татар Мөшегесе торак пунктында авыл паркы территориясен төзекләндерү (койма

урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әтрәкле авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районы https://menzelinsk.tatarstan.ru/atraklinskoye.htm сайтында бастырып чыгарырга хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Газизҗанов

ОГРН 1021605552836
р 06-114/09
Совет
АТРЯКЛИНСКОГО
сельского поселения
ИНН 162800286